ХАЛЫК ӨЧЕН

Федераль грант акчасын кече шәһәрләр нәрсә өчен тотачак?

> 2

ЯКЫНАЙСЫН АРА

Китапны укучыга якынайту чаралары күптөрле. Кулланабызмы соң?

> 3

СЫЛУЫМ-ИРКӘМ...

Татарны «Галиябану»лы иткән авылда халык театрлары чыгыш ясады

> 4

АЙРАТ ВИНОГРАДЛАРЫ

Җан тынычлыгы эзләп тотынган шөгыльдән – керемле кәсепкә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 123 (28896) | Чәршәмбе | 24 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

Яшәеш

ТҮБӘН КАРАЧ ӨМЕТЕ

Элек җиде мәчетле, җиде урамлы авылда бүген берничә кеше генә яши. Юк, бу – төш түгел, ачы чынбарлык. Әгәр туган нигез, дип яшәүче фермер Тәлгать абый Арысланов булмаса, Актаныш районының Түбән Карач авылы картадан күптән юкка чыккан булыр иде. Авылны саклау өчен, әллә нинди планнар корып яши ул. Үз дигәненә ирешә алырмы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кайда сез, кешеләр?

«Карач» сүзе күңелне әллә ничек шомландырып куйса да, авыл сине үзгә бер яктылыгы, тынлыгы белән каршы ала. Ерактан ук җилфердәгән әләмнән монда ватанпәрвәрләр яшәве күренә. Бер ел элек Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл ачканнар.

Соңгы елларда сигез йорт булса, бүген аларның саны – бишәү. Шуның икесендә генә кыш чыгалар, калганнарына авылдашлары җәен кайткалап йөри. Ансаф абый туган нигезеннән бөтенләй китеп тормаган. Ул Тәлгать абыйның икенче буын туганы икән. Тугызынчы дистәсен ваклаучы Шәфыйковлар өчен дә кадерле урын бу. Нәсимә апа белән Рифкать абый, яз башында кайтып, Чаллыга көзен генә китәләр. Кышын да торыр идек, мөмкинлекләр генә юк, диләр.

Авылның бормалы урамын ураганда, башта бары бер уй бөтерелде: «Шаулап торган авыл ничек беткән соң?» Бу сорауга төгәл генә җавап бирүче юк. Әмма сәбәбен фаразлаучылар бар. Авыл кешеләре моны эшсезлек, юлсызлыкка бәйләп аңлата. Язучы, тарих фәннәре докторы Ягъсуф Шәфыйков «Ишан хәзрәт наратлыгы сере» дигән тарихи хикәясендә: «XIX гасыр ахырында авылыбыз бик зур булган. Җиде урам мәхәлләсендә җиде мәчет манарасы балкыган», – дип язган. Анда 1920 елда – 226, 1958 елда – 50, 1965 елда 59 (16 өйдә) кеше яшәгән. 1993 елда йортлар саны өчкә кала, 2010 елда 4 йортта 8 кеше гомер кичергән. 1921–1922 елгы ачлык чорында 106 кешегә кимеп, халык саны азая барган. Бөек Ватан сугышына Түбән Карачтан 16 ир китсә, шуларның 11е яу кырында ятып калган.

Туган нигез

Бүген кечкенә авылның яңа сулыш алып ятуы. Тәлгать Арысланов туган авылына 15 ел элек күченеп кайткан. Аңа кадәр дә эзләрен суытмаган, атна саен кайтып йөргән. Чаллыда төрле урыннарда эшләгән, таксида йөргән, яшелчә-җиләк-җимеш саткан ул. Хәзер фермерның 150 гектар җире бар.

– Шушы авылда туып-үстем. Хәзерге вакытта мин гөлҗимеш төнәтмәләре эчеп, кыштыр-мыштыр гына йөреп, лаеклы ялда булырга тиеш идем. Тик хөкүмәт пенсия яшен арттырып куйды бит, – дип, сүзен уены-чыны белән башлады 61 яшьлек Тәлгать абый. – Бездә бит крестьян холкы, шуңа күрә җирдән тәм табып яшибез. Актанышка барсам да, тизрәк авылга кайтасы килә башлый. Монда бик рәхәт. Туган нигезне ярату хисе тартты мине авылга. Хатыным Зөлфирә белән яшибез. Бер кыз үстердек. Туган нигезне яңартып, мичләрен чыгардык. Күршегә ике катлы йорт салдык. Берсе генә җитмәдемени, дисез. Ир кеше үз гомерендә йортын да салырга, агачын да утыртырга тиеш. Мин дә калышырга теләмәдем. Тик менә улыбыз гына булмады.

Тәлгать абый авылда яшәүнең рәхәтен башкаларга да җиткерергә тели, авылдашларын да кайтырга чакыра ул. «Ватсап»та «Авылым туган ягым» дигән төркемне булдырган, анда шушы авылдан чыккан 300ләп кеше теркәлгән. Авыл күренешләрен фото, видеога төшереп, карачлыларга бар яңалыкларны җиткереп тора. «Мин аларга авылда яшәү өчен мөмкинлекләр барлыгын исбатларга тырышам», – ди. Тик әле кайтам дип торучы берәү дә юк, серләрен ачмыйлар икән. Шул ук вакытта: «Бөтенебезне дә чакырасың, каян эш табарсың соң?» – диючеләр дә бар.

Тәлгать абый кебек эш яратучылары гына кайтса инде. 2010 елда крестьян-фермер хуҗалыгы оештырган ул. Башта 8, аннан 16 баш терлек тоткан. Бүген 150 баш сарык асрый, аны корбанлык итеп тә сата. 50ләп кәҗәсе бар. «Иртүк сәгать 4тә торам. Кәҗәсен дә, сыерын да үзем савам. Сарыклар көтүдә, караңгы төшкәч кенә кайталар. Махсус көтүчебез бар, ул да шушы авылда яши, – дип сөйли ул эше турында. – 22 гектар мәйданда бәрәңге игәбез. Районда ике хуҗалыкта гына үстергәч, сораучылар бар. Башка авыллардан да килеп сатып алалар. Быел бер айдан бирле яңгыр төшмәде инде. Уңышы ничек булыр, белмим».

Ахыры 2 нче биттә >

Эшсезләр йөрмәс төркем-төркем

Оешмаларга 30 яшькә кадәрге эшсезләрне эшкә урнаштыруга ярдәм итү программасы киңәйтелгән. Моңа кадәр бары тик аерым категория кешеләр генә дәүләт ярдәменә исәп тота алган.

Россия Хөкүмәте матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, субсидия күләме (хезмәткә түләүнең 3 минималь күләмен тәшкил итә) район коэффициентына, иминиятләштерү взнослары суммасы һәм эшкә урнашучылар санына тапкырланачак. Шул ук вакытта оешма тәүге түләүне – хезмәткәр эшкә урнашканнан соң бер ай узгач, икенчесен – өч ай узгач, өченчесен ярты елдан соң алачак. Эш бирүчеләр ярдәм алу өчен мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итәргә тиеш.

Моннан тыш, Хөкүмәт эштән җибәрелү куркынычы алдында калучыларны эшсезләр сыйфатында теркәү таләбен юкка чыгарган. Исегезгә төшерәбез: Министрлар Кабинеты яз көне халыкны эшле итүгә 40 миллиард сум чамасы акча биргән иде.

Акча булачак

Пляжларны үстерү-төзекләндерү һәм туристлык маршрутларын булдыруга акча табылачак. Татарстан Туризм буенча федераль агентлыктан ярдәм алырга тиешле төбәкләр исәбенә эләккән. Бу максатта 44 төбәккә барлыгы 3,1 миллиард сум бүлеп бирелә. Республика шуның 143 миллион сумын алачак. Ростуризм башлыгы Зарина Догузова үзенең телеграм-каналында шул хакта хәбәр иткән.

Татарстан Туризм буенча дәүләт комитетында әйтүләренчә, грант ярдәменә гариза республика бюджетыннан да акча өстәләчәген күздә тотып тапшырылган. Субсидия бирүгә бәйге киләсе елда оештырыла.

Гомумән алганда, Ростуризм 44 субъектның 375 проектын тормышка ашыруга ярдәм итүне күздә тота. Шул ук вакытта федераль агентлык грантларының гомуми күләме 5,3 миллиард сум тәшкил итәчәк. Пляжларны һәм туристлык маршрутларын карауга 3,1 миллиард сум тотылачак. 10 төбәктә кемпинг һәм автокемпинг үстерүгә тагын 700 миллион сум биреләчәк. Моннан тыш 21 төбәкнең 500дән артыграк проектын (инвалидлар өчен туристлык мохитен үстерү, яңа туристлык маршрутларын эшләү проектлары һ.б.) гамәлгә ашыруга 1,55 миллиард сум күләмендә акча биреләчәк.

Мәгълүмат иминлеге

Риза, дисәң әгәр...

Цифрлы суверенитет, цифрлы кодекс, ясалма интеллектны куллану – Россия Президентының кеше хокуклары буенча советы тарафыннан цифрлы мохиттә кеше хокукларын һәм иреген яклауны тәэмин итү концепциясендә сүз шулар хакында бара.

Цифрлы мохиттә халыкның хокук һәм иреген тәэмин итү турында сүз күптәннән бара инде. Аерым алганда, 2020 ел азагында Россия Президенты үзе үк бу өлкәдә нигез булып торырлык документ әзерләргә кушкан иде. Бу эш белән Россия Президентының кеше хокуклары буенча советы шөгыльләнде. Алар әзерләгән документның максаты – мәгълүмат технологияләренең тиз үсеше, икътисадның һәм дәүләт идарәсенең цифрлы үзгәреше һәм кеше хокуклары арасында алтын урталыкны саклау. Концепцияне тиздән ил башлыгына тәкъдим итәчәкләр.

Сер түгел, никадәр генә тырышсак та, шәхси мәгълүматны саклау кыен. Аңа йозак элеп куеп та булмый. Замана алга киткән саен, мәгълүмат уртаклашу һәм аның башкалар кулына килеп эләгүе дә гел күзәтелә. Белгечләр әзерләгән концепциядә мәгълүмат иминлеге турында нәрсә диелә, нинди тәкъдимнәр кертелә соң? Иң мөһимнәренә тукталыйк.

Цифрлы суверенитет. Документта шәхси мәгълүматны куллануга бәйле өлешкә шактый игътибар бирелгән. Белгечләр әйтүенчә, шәхескә үзе турында булган мәгълүматны кире алу һәм цирфлы мәйданчыктан юк итү хокукын бирергә кирәк. Ул катлаулы булырга тиеш түгел, мөмкин кадәр җайлы һәм гадиләштерелгән ысул белән эш итү күздә тотыла.

«Социаль рейтинг» дигән төшенчә дә булмаячак. Белгечләр сүзләренчә, андый база, рейтинглар барлыкка килү белән, шулардан явызларча файдаланучылар артачак, мәгълүматны сату яисә үз мәнфәгатьләрендә кулланучылар күбәячәк. Билгеле булганча, социаль рейтинг алымын Кытайда кулланалар. Компьютер кеше турында мәгълүматны туплап анализлый. Монда шәхеснең закон белән ни дәрәҗәдә дус булуы да, тормышының башка яклары да исәпкә алына. Рейтингтагы түбән баллы кешеләргә башка чикләүләр дә каралган.

Аерым игътибар. Цифрлы дөньяга баштанаяк чуму иҗтимагый фикер белән идарә итү мөмкинлеген киңәйтә. Шулай ук яңа куркыныч социаль күренешләр, зарарлы эчтәлекле контент барлыкка килүгә дә юл ача. Концепциядә әйтелгәнчә, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният тармакларының тиз арада цифрлашуы бер яктан яхшы да, икенче яктан – сынау да. Беренче чиратта балаларны цирфлы бәйлелектән саклау кирәк. Шулай ук өлкәннәрнең самими беркатлылыгыннан явызларча файдалануны булдырмаска.

Президент советындагыларны кирәксә-кирәкмәсә дә кешеләрдән биометрик мәгълүмат җыю мәсьәләсе дә борчый. Белгечләр әйтүенчә, куркынычсызлыкны тәэмин итү максатыннан, бу эш белән җаваплылыкны үз өстенә алырлык җитди хезмәтләр генә шөгыльләнсә – бер хәл. Мәгълүматның мондый төрен туплау сәбәбе нигезле булырга, нинди мәгълүматны һәм кемгә тапшырасын шәхес тик үзе генә хәл итәргә хокуклы булырга тиеш.

Сүзгә-сүз

Владимир ЖАВОРОНКОВ, Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары:

Татарстанда күмәк иммунитет дәрәҗәсе 3,9 процентка төште. Февраль аенда бу күрсәткеч 83 процент иде. Әмма инфекция беркая да китмәде бит. Кабат вакцина ясату эшен башларга кирәк. Әгәр без алга таба да уңайлы шартларда яшәргә һәм эшләргә телибез икән, бу – үз-үзебезне һәм әйләнә-тирәдәгеләрне саклауның бердәнбер ысулы.

РОССИЯДӘ – ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР

Соңгы 10 елда гадәттән тыш хәлләр вакытында Россиядә 6 меңнән артык кеше һәлак булган. Бу хакта гадәттән тыш хәлләр министрының беренче урынбасары Александр Чуприян хәбәр итте.

10 ел эчендә булган гадәттән тыш хәлләр саны >> **3,2 мең**

НИНДИ ҺӘЛАКӘТЛӘРДӘ ҮЛӘЛӘР?
(2021 елга караган мәгълүматлар буенча)

Табигый гадәттән тыш хәлләр	**4,5%**
Техноген һәлакәтләр	**95,5%**
Биологик-социаль гадәттән тыш хәлләр	**ЮК**

Үзебездә җитештерәсе

Татарстанда санкцияләр хөкем сөргән бер мәлдә импортны алыштыру өчен кирәкле продукция исемлеге расланган. Исемлек 1792 пункттан тора. Республика Премьер-министры Алексей Песошин тиешле карарга кул куйган.

Импортны алыштыру өчен кирәкле товарлар исемлегенә руда һәм төсле металл концентратлары, табигый сумала, крахмал, чүпрә, терлек өчен әзер азык, хәмер эчемлекләре, синтетик тукыма, агачтан ясалган әйберләр, целлюлоза, монитор, проекторлар һ.б. кергән.

Исегезгә төшерәбез: Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы май аенда параллель импорт өчен товарлар исемлеген раслады: аларны бренд хуҗасы ризалыгыннан башка гына илгә кертергә мөмкин. Исемлектә, аерым алганда, җылылык казаннары, электроника, «акыллы» сәгатьләр, музыка кораллары урын алган.

Игътибар: балалар!

Быелның 7 аенда Татарстан юлларында 16 яшькә кадәрге балалар катнашында 245 юл һәлакәте килеп чыккан. Аларда 7 баланың гомере өзелгән, 258 бала төрле дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре алган. Август – сентябрь айларында балалар катнашындагы юл һәлакәтләре саны бермә-бер арта, дип кисәтә белгечләр. Шуңа күрә 22 августтан 11 сентябрьгә кадәр Татарстанда «Игътибар: балалар!» дип исемләнгән профилактик чара уздырыла. Аның кысасында профилактик чаралар үткәрү, аңлату эшләре алып бару, рейдлар үткәрү күздә тотыла.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АЗЫК-ТӨЛЕККӘ БӘЯЛӘР ТӨШӘ, ӘММА ФРАНЦУЗЛАР БӘРӘҢГЕСЕЗ

Глобаль икътисад кризисы торган саен үзен ныграк сиздерә. Авыр хәл һәм турбулентлык нигездә энергия чыганакларына кискен күтәрелгән бәяләр аркасында формалаша.

Пакыстанның күп кенә шәһәрләрендә үткән тәүлекләрдә халык протест белән урамнарга чыкты. Кешеләр электр энергиясенә бәяләрнең югары булуыннан риза түгел. Җитмәсә, ут бик еш өзелә. Тәүлеккә 12–16 сәгать утсыз утырган чаклар була икән. Исламабад кризисы Европадагы газ проблемасына тыгыз бәйләнгән. «Газпром» краннарны ябып куйганнан соң, Европа күпләп сыеклandырылган газ сатып ала башлады. Танкерлар кем күбрәк түли, шуңа таба йөзәләр. Нәтиҗәдә Азия базарларында, аеруча Пакыстан белән Бангладешта, газ җитешми. Бу, үз чиратында, электр энергиясенең дефицитын тудыра.

Газ проблемасы Көнбатышның үзендә дә кискен булып калуын дәвам итә. Европада күп кенә алюминий һәм цинк заводлары энергия чыганакларына бәяләр югары булу сәбәпле ябылалар. Хәзерге газ бәясе белән шикәр җитештерүгә караганда, заводларны ябып кую отышлырак, диләр Европада. Ихтимал, башка товарларны җитештерү дә шул сәбәпле зыянлы була башлар.

Икътисади проблемалар Евросоюз валютасын очсызландыра. Евро доллар белән тигезләште һәм аннан да түбәнрәк бәягә сатыла башларга җыена. Бер елдан соң аның бәясе 2001 елгы дәрәҗәгә түбәнәер һәм долларга 0,83 евро бирә башларлар дип фаразлыйлар. Финанс кыенлыклары Европа державаларында азык-төлеккә бәйле проблемалар китереп чыгара. Иң яшь француз милли газетасы «Либерасьон», Франциягә котылгысыз рәвештә бәрәңге, бал һәм сөт дефициты яный, дип яза.

Глобаль кризисның авазы АКШта да көчлерәк ишетелә. Анда йортлар сату кими. Тик шулай да тормышта барысы да начар түгел. Күпме генә, корылык нәтиҗәсендә ачлык булачак, дип куркытмасыннар, планета масштабында бөртеклеләргә бәяләр түбәнәя. Азык-төлек бәяләренең глобаль индексы инде дүртенче ай рәттән кими икән. АКШ Авыл хуҗалыгы министрлыгы бодай уңышы узган елдагыдан яхшырак булачагын белдерә. Дүшәмбе биржаларда шуңа күрә бәяләр май пигыннан 60 процентка төшкән. Кара диңгездән украин ашлыгы чыгарыла башлау да бәяләрнең очсызлануына китерә. Россиядә икмәк уңышы яхшы булуы көтелә. Июльдә планета масштабында бөртеклеләргә генә түгел, сыек майга, шикәргә, ит һәм сөткә бәяләр төшкән. Шулай да бер нәрсәне истә тотарга кирәк: быелгы июльнең түбәнәйгән бәяләре 2021 ел июленең бәяләреннән күпкә югары булып калуын дәвам итә. Бодай бәясе, мәсәлән, 24,8 процентка югарырак булып кала. Сөт бәясе дә шулай ук. Быелның июне белән чагыштырганда сөт бәясе түбәнәйгән, әмма үткән елның шул чоры бәясеннән 25 процентка югарырак.

БМО белгечләре, глобаль ачлык проблемасы саклана, дип белдерә шуңа күрә. Азык-төлек кризисыннан чыгу тиз генә булмас, диләр.

Россиядә

СУМНЫ ЮАНЬ БЕЛӘН КӨЧСЕЗЛӘНДЕРҮ

Россиянең финанс базарында хәлләр гаҗәпләндерә торган, сөенечле түгел. Кәгазь доллар һәм евро дефицитта, ә электрон хисаптагы резерв валюталары бернигә дә ярамый диярлек. Бездә аларны рәсми рәвештә дә кәнфит кәгазе – фантиклар дип атап йөртә башладылар.

Фантиклар берәүгә дә кирәкми, шул сәбәпле сумның курсы аларга карата ныгый. «Рубль – көчле валюта» дигән иллюзия туа. Әмма аның шулай куәтле булуы финанс хакимиятләренә бер дә ошамый. Бер долларга 60 сумнан да югарырак булган рубль курсы бюджетны дефицитлы итә, төп сәнәгать тармакларын егып ук сала. Рубль доллар бәеннән ычкынды, дип әйткән булабыз тагын. Баксаң, файдалы казылмалар чыгару да, урман кисү дә, металл кою да доллар курсына бәйле икән. Үзеңнең технологик продуктларың, технологик экспортың булмагач, доллар диктатына буйсынмый булмый. Россия банкларындагы доллар хисапларын чит илләргә күчерә алсаң, Америка кәгазе шунда ук фантик булудан туктый. Тимер пәрдәнең теге ягында ул һаман да кадерле валюта әле. Шуңа күрә хәлле россиялеләр валюталарын дус илләрнең берәрсендә саклауны хуп күрә. Июнь аенда физик затлар рекордлы күләмдә валютаны чит илгә озаткан. Бер айлык валюта күчерү 4,7 миллиард долларга җиткән. Казахстанга 140 млн доллар качкан, мәсәлән. 2021 елда җәй айларында Россиядән Казахстанга уртача айга 12 млн доллар чыгарылуын исәпкә алсак, казах банкларының россиялеләр өчен коткару тәгәрмәче ролен үти башлавын күрербез.

Илдә калган долларлар һаман да кирәгеннән артык күп. Финанс министрлыгы элеккечә доллар һәм евро сатып алып, курсны түбәнәйтә алмый, чөнки бу акчаны суга салуга тиң. Вашингтонга Россия банклары хисабындагы валютаны туңдыру берни дә тормый, чөнки электрон долларны Америка банкында корреспондент хисабың булганда гына файдаланып була. Моны дөрес аңласак, без Россиянең бөтен доллардагы экспорты чынлыкта бушка икәнен күрә алабыз. Товар бирмиләр генә түгел, теләсә кайсы мизгелдә ул акчаны парга әйләндерә алалар. Шул сәбәпле кайсы ил нинди кәгазь бирсә, кыйммәтле чималны шуңа сатып азапланабыз. Юаньга өстенлек бирелә инде, гадәттә. Ни дисәң дә, бердән, резерв валютасы булып санала, икенчедән, Кытай – дус илләр исемлегендә.

Сумның югары курсы Россия финансларын тәмам эштән чыгара. Хөкүмәт, курсны түбәнәйтү өчен, бюджет кагыйдәсен яңадан кайтарырга ниятли. Нефть бәясе 60 доллардан артканда, валюта интервенцияләрен яңадан кайтарырга булдылар. Тик бу юлы доллар-евро түгел, ә Кытай юаньнарын сатып алып, казна капчыгына тутырып, авызын ныклап бәйләп куярга җыеналар. Халыкка да, бюджетка да юк, технологияләр үстерү өчен дә түгел. Мөгаен, Кытайның әҗәт кәгазьләрен сатып алырлар. Кытай икътисадына печтек кенә сулыш бирер ул адым, безнекенә – юк. Әмма сумның курсы түбәнәеп, бюджет дефицитын киметер дигән өмет бар. Моның өчен күпләп сумнар басарга туры киләчәк. Кытай белән араларны бозарга ярамый инде бер дә. Югыйсә Пекин да Вашингтон эшләгәнне кабатларга мөмкин.

БАЛАЛАРГА – БАКЧА, КЫР УҢГАННАРЫНА – МАКТАУ

Яңа балалар бакчасы, полиция участогы, аграрийлар шатлыгы. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин Зәй районына эшлекле сәфәр кылды.

tatarstan.ru

Премьер-министр кыр эшләре белән танышты, авыл хуҗалыгы предприятиеләре, авыл җирлекләре башлыклары белән очрашты.

Район башлыгы Рәзиф Кәримов сүзләренчә, Зәйдәге урып-җыю мәйданы 36,7 мең га тәшкил итә. Яртысыннан артыгын – 21,4 га мәйданнан 105 мең тоннадан артык уңыш җыеп алганнар. Район җитәкчесе мөгезле эре терлек, сөтчелек тармагына бәйле саннар белән дә таныштырды, мини-ферма, хуҗалыклар эше турында сөйләде.

Алексей Песошин әйтүенчә, Зәй – авыл хуҗалыгы тармагы буенча алдынгы районнарның берсе. «Урып-җыю күрсәткече буенча да, уңыш буенча да сез – иң яхшылар арасында. Зур агрофирмалар, инвесторлар бар. Хезмәтегез өчен рәхмәт», – диде ул.

Кырдагы эшләр белән танышканнан соң, Алексей Песошин төзекләндерелеп ачылган «Якты коңгыз» балалар бакчасын карады. Бакча 150 урынга исәпләнгән.

Моннан тыш Алексей Песошин төзекләндерүдән соң полиция бүлеге ачылышында катнашты. Премьер-министр искәрткәнчә, хокук саклау хезмәткәрләрен яхшы хезмәт шартлары белән тәэмин итү – хакимият органнары өчен иң мөһим бурычларның берсе. Агымдагы елда район территориясендә ачыкланмаган кеше үтерү, аңлы рәвештә сәламәтлеккә зур зыян китерү һәм башка авыр җинаятьләр кылынмаган.

АКЧАГА ЭШ ТАБЫЛА

510 миллион сум. Татарстанның 6 шәһәре әнә шулкадәр суммада грант откан. Кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр арасында уздырылган илкүләм бәйгедә катнашу өчен, республикадан барлыгы 7 шәһәр гариза тапшырган булган. Җиңү бәхете Болгар, Зәй, Яшел Үзән, Алабуга, Лаеш һәм Лениногорскига тәтегән.

Дөрес, әлеге шәһәрләр бу бәйгедә беренче тапкыр гына катнашмый. Алар 2020, 2021 елларда да бәйгедә катнашуга гариза тапшырган булган. Җиңә алмаганнар, әмма янә көрәшергә карар кылганнар. Быел исә бу проектларны яңадан тикшереп, бәйгедә катнашкан шәһәрләр территориясендә төрле чаралар да уздырылган. «Татарстан шәһәрләре үсеше институты» фондының шәһәр мохитен үстерү программалары кураторы Наилә Зиннәтуллина сүзләренә караганда, быел җиңә алмаган Мамадыш киләсе бәйгедә кабат катнашачак. Моны район башлыгы Анатолий Иванов та раслады. Бу җәһәттән районда киләсе елга зур эшләр планлаштырылган. Аерым алганда биредә тау битләрен тигезләп, чаңгычыларны тауга менгерәчәк җиһазлар урнаштырырга ниятлиләр. Киләсе бәйгедә Әлмәт тә катнашырга җыена.

Инде җиңүчеләргә килгәндә, грант акчасы җирле иҗтимагый киңлекләрне төзү-төзекләндерү, тарихи урыннарны яңарту өчен тотылачак. Яшел Үзәндә, әйтик, грант Алтынов исемендәге паркны төзекләндереп, уңайлы маршрутлар ярдәмендә шәһәрнең иске һәм яңа өлешләрен тоташтырырга җыеналар.

Алабуга районында бәйгедә откан 95 миллион сум грант ярдәмендә шәһәрдәге Шишкин буасы территориясе халыкка җәен генә түгел, ел әйләнәсе хезмәт күрсәтәчәк. Райондагы традицион Май чабу бәйрәме дә быел нәкъ менә биредә узачак. Бәйгегә гариза тапшырыр алдыннан уздырылган бәйрәмдә барлыгы 2,5 мең кеше катнашкан. Җирле эшмәкәрләр исә чара барышында 500 мең сум табыш алган.

Грант откан башка район-шәһәрләрнең дә планнары зурдан. Лениногорскида, әйтик, Менделеев урамында урнашкан буалар каскадында спорт кластеры булдырылачак. Аерым алганда биредә рекреацион-сәламәтләндерү маршруты пәйда булачак. Зәйдә исә яңа «Яшьләр» паркы барлыкка киләчәк. Анда тамп-трек, паркур зонасы белән Яшьләр үзәге дә булачак. Лаешта грант акчасын «Ак таулар» мәдәни-рекреация кластеры булдыруга, Болгарда «Спас Болгары» шәһәренең социаль-мәдәни үзәген төзекләндерүгә тотмакчылар.

Нурлатта бәйгедә җиңү яулаганчы ук зур эшләр башкарылган булган. Алар бу бәйгедә 2018 елда да катнашып, грант откан. Ул чакта шәһәр үзәгендәге Карл Маркс урамын төзекләндергәннәр. Район башлыгы Алмаз Әхмәтшин сүзләренә караганда, дүрт ел элекке урам белән хәзергесе арасында – җир белән күк аермасы. Элек иске генә караңгы бу урамда җәяү йөрү өчен дә, машина кую өчен дә бернинди шартлар булмаган. «Элек бу юлны халык эш буенча гына таптый иде. Хәзер ул кичке сәгать алтыдан соң да гөрләп тора. Хәзер биредә 18 эшмәкәр үз эшен җәелдерә. Көз көне бу урамда тагын бер кафе, милек агентлыгы белән матурлык салоны да эшли башлаячак», – ди район башлыгы.

2020 елда Нурлатның Кондырча елгасы буенда ял паркы да шушы ук бәйгедә грант откан булган. Ике ел эчендә биредә махсус җиһазландырылган су коену һәм ял урыны, шашлык пешерү зонасы, прокат нокталары белән кибетләр барлыкка килгән.

Исегезгә төшерәбез: кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр арасында уздырылган илкүләм бәйгедә Татарстан инде алтынчы тапкыр катнаша. 2018 елдан бирле әлеге бәйгедә республикадагы 38 җәмәгать урыны җиңү яулаган. Шул вакыттан бирле республиканың кече шәһәрләре барлыгы 2,5 миллиард сум грант откан.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Номинация	Шәһәр	Грант күләме
«50 меңнән 100 меңгә кадәр кеше яшәгән кече шәһәрләр»	Алабуга, Шишкин буасы	95 миллион сум
	Яшел Үзән, Алтынов ис. парк	95 миллион сум
	Лениногорск, Менделеев урамында урнашкан буалар каскадында спорт кластеры	95 миллион сум
«20 меңнән 50 меңгә кадәр кеше яшәгән кече шәһәрләр»	Зәй, Яшьләр паркы	85 миллион сум
«Халкы 20 меңнән артмаган кече шәһәрләр»	Лаеш, «Ак таулар» мәдәни-рекреация кластеры (Семрук)	70 миллион сум
	Болгар, «Спас Болгары» шәһәренең социаль-мәдәни үзәге	70 миллион сум

ТҮБӘН КАРАЧ ӨМЕТЕ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Донбасстан безгә кайтсыннар»

Без килгәнне белеп, яныбызга ак яулыгын бөркәнгән 84 яшьлек Нәсимә апа да килеп җитте. Рифкать абый белән 67 ел бергә матур гомер кичерәләр икән. Нәсимә апа Чаллыда ике килене, ике улы белән яши. Дүрт ул тәрбияләгәннәр.

– Себердә туганмын, шунда куылган гаилә баласы мин. 1956 елда Түбән Карачка килен булып килдем. Ул вакытта 15ләп йорт исәпләнә иде монда. Кибет бар иде, ул да калмады. Мәчетне мәктәп итеп тоттылар, – ди ул, яшьлеген искә төшереп. – Фермада сарыклар карадым. Әмма юл булмагач, торакларны сүтеп алып киттеләр. Пенсиягә чыкканчы, ат белән Яңа Кормашка барып, фермада эшләдем. Эш булса, авылда калган булыр идек. Безнең 4 малай да чыгып китмәс иде. Юл булмагач, авыл бетте. Әгәр мөмкинлекләр булса, авыл бу хәлгә үк төшмәс иде. Нигә Донбасстан күченеп килгән кешеләрне безгә китермиләр икән ул? Авыл үсеп китәр иде, ичмаса. Бездәге халык бик әйбәт иде, хәзер дә шулай.

«Авылдан бер дә китәсем килми, әмма мөмкинлекләр булмагач, бернишләп тә булмый, – ди Нәсимә апа. – Картларга гына түгел, яшьләргә дә... Менә шушы бала (Тәлгать абыйга төртеп күрсәтә. – **Ред**.), тырышып, өй салды. Аның шәһәрдә дә фатиры бар иде югыйсә, авылны бик ярата. Түбән Карачны шул яшәтә. Бәлкем, минем дә бер улым кайтыр иде, әгәр газ, юл булса... Зиратның коймасы юк, ялан җирдә урнашкан ул. Тирә-ягы балчык белән әйләндереп алынган. Без, пенсионерлар, үзебез дә ярдәм итәр идек. Коръән ашларында да әйтеп карадык, тик ишетүче булмады. Күпләргә мәгълүм булган ишан хәзрәт Ягъфәр Сабучы (1838 елда вафат булган. – **Ред**.) шушы авылда күмелгән».

Безне озата килгән Татар Суыксуы җирлеге башлыгы Гүзәл Хамматуллинаның бу хакта беренче ишетүе икән. «Койманы бергәләп тотарбыз, эшләмәслек эш түгел бит», – диде ул, өмет биреп.

Авылга – туризм

Авыл бетә дип утыра торганнардан түгел Тәлгать абый. Дөрес, киләчәге бүгенге рәвештә генә сакланса да, бик сөенер иде ул. Үзенең хыяллары да зурдан. Атлар сатып алып, авыл туризмын җәелдерәсе килә аның. Биектау районының Ямаширмә авылындагы кебек кәҗә, сарык, дөя, тәвә кошы һәм башка җәнлекләр фермасы ачарга нияте дә юк түгел. «Кормаш балалары монда килеп уйныйлар, чәй эчәләр. Башкалар да автобуслар белән килерләр иде, – ди ул. – Туристлар өчен дә менә дигән ял итү урыны бу. Чатырлар корып, глэмпинг яки кунакханә ачарга мөмкин. Шәһәр кешесенә авылда ял итү тансык бит ул. Ыгы-зыгы юк, минем үземне бер дә туйдырмый авыл».

Кунакка килү – бер, әмма анда яшәү – икенче нәрсә. Тәлгать абый әйтүенчә, авыл ул – җирне яратучылар өчен. Әгәр кеше шуны аңласа, үзмәшгуль булып теркәлеп тә эшен башлап җибәрә ала. Әйтик, берничә баш сыер асрап, сөтен сатарга мөмкин. Үзе ул көнгә 30 литр сөт савып тапшыра. Игенчелек белән дә авылны саклап була, ди. Моның өчен авылга кайтырга теләк кирәк башта. Әнә Тәлгать абый Түбән Карачның данын еракларга тарата. Анда фермерлар Сабан туе уздырган. Фермерлар исә балалар Сабан туе уздырыр өчен акча биргән. Мондый бәйрәмне күптән күргәне булмаган авылның. Ашы белән җыры да кайткан түгелме?

КҮПЕР САЛУЧЫЛАР

Яшәеш

«Кешеләр сезгә ныграк ышана». Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстандагы социаль юнәлештәге коммерциясез оешмалар эшчәнлегенә әнә шундый бәя бирде. Ярдәм итеп кенә калмыйлар, алар дәүләт белән халык арасына күпер сала. Бу хакта әлеге оешмаларның Казанда узган V республика форумының пленар утырышында сөйләделәр.

vk.com

– Без һәрвакыт социаль юнәлештәге коммерциясез оешмалар белән элемтәдә торабыз. Очрашуның яңа форматларын уйлап табабыз. Әле яз башында гына җыелган идек. Менә тагын күрешергә насыйп булды. Шунысын әйтә алам: эшегездән бик канәгатьбез. Уйланган эшләрне актив кешеләр белән бергәләп тормышка ашырабыз, – диде Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин. – Утырышка килер алдыннан, Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов белән күрештек. Ул да, без – дөрес юлда, дигән фикердә. Социаль юнәлештәге коммерциясез оешмалар һәрвакыт халык ихтыяҗларын кайгырта. Сез – халык белән дәүләтне тоташтыручы җеп. Үзегез күреп торасыз: илдә төрле хәлләр булгалый. Без һәр очракта да дөрес карар кабул итәргә тиеш.

Фәрит Мөхәммәтшин иҗтимагый оешмаларның республикада милләтләр һәм диннәр арасындагы дуслыкны ныгытудагы өлешен дә искә алды. «Бары бездә генә татар бәйрәмендә чуаш халкы җырлап бии, руснықында татар күңел ача, – ди ул. – Бу оешмалар нинди генә эш алып бармый. Алар ватанпәрвәрлекне дә кайгырта, авыру балаларга да ярдәм итә. Берәү бер җыр җырлап, икенчесе башканы сузса, начар булыр иде. Без һәрвакыт сездән тәкъдим көтәбез. Шуны онытмагыз: сезгә кешеләр ныграк ышана».

Фәрит Мөхәммәтшин авыл хуҗалыгы юнәлешендә дә күбрәк эшләргә киңәш итте. Сер түгел, авылларда калучылар көннән-көн кими. Дәүләт Советы Рәисе, мал асраучыларга ярдәм хакында кат-кат сөйләргә кирәк, дигән фикердә. Авыл җирендә яшәүче гаиләләр өчен федераль һәм республика программалары хакында да аңлатырга кушты.

– Авылда гына тел дә, бәйрәмнәр дә, гореф-гадәтләр дә саклана. Кеше шәһәргә китә икән, бар да югала. Шуңа күрә авылларда да яхшы яшәр өчен мөмкинлекләр барын аңлатырга кирәк, – диде ул.

Россия иҗтимагый палатасының социаль юнәлештәге коммерциясез оешмалар үсеше комиссиясе рәисе Елена Тополева-Солдунова әйтүенчә, әлеге оешмалар эшчәнлеге буенча Татарстан өченче урында тора. Бу – яхшы күрсәткеч, диде ул һәм, форсаттан файдаланып, утырышта катнашучыларны «Сообщество» форумына чакырды.

Татарстанның Иҗтимагый палатасы җитәкчесе Зилә Вәлиева V республика форумының инде 5 июльдән бирле эшләгәнен әйтте.

– Тынгысыз кешеләрнең күптән бергә җыелганы юк иде инде. Без форумны төрле җирлектә уздырдык. Очрашулар Казан, Чаллы, Алабуга, Әлмәт шәһәрләрендә, Актаныш, Спас районнарында узды. Бүген шуларга нәтиҗә ясыйбыз. Очрашуларда 130дан артык тәкъдим җыелды. Барысы да резолюциягә кермәскә дә мөмкин. Әмма без бер генә сорауны да читтә калдырмаячакбыз, ул юнәлешләр буенча эшләячәкбез, – ди Зилә Вәлиева. – Республикада 6 меңнән артык социаль юнәлештәге коммерциясез оешма теркәлгән. Аларның һәркайсының үз юнәлеше бар. Мин Россия буенча өченче урында булуыбыз белән килешеп бетмим әле. Моны төзәтергә кирәк.

Зилә Вәлиева бездә иң яхшы эшләгән оешмаларга Татарстан Президенты премиясе бирелүе хакында да сөйләде. Мондый ярдәм булганда, һәркемнең күңеле үсә, ди ул:

– Быел социаль юнәлештәге коммерциясез оешмалар өчен уздырылучы бәйгеләр берләштерелде. Әле анда катнашырга теләүчеләрнең 28 августка кадәр гариза бирергә вакыты бар. Грантларның гомуми суммасы 106 миллионны тәшкил итә.

Очрашуда әлеге оешмаларның проблемалары – салым түләү, бина табу, аренда чыгымнарын каплау кебек мәсьәләләрне хәл итү кирәклеге турында сөйләштеләр. Зилә Вәлиева исә һәр сорауны искә алачакларын, алга таба да бергә җыелып сөйләшәчәкләрен әйтте.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БЕР МАНДАТЛЫ САЙЛАУ ОКРУГЫ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ӨСТӘМӘ САЙЛАУГА ТЕРКӘЛГӘН КАНДИДАТЛАРНЫҢ САЙЛАУ АЛДЫ АГИТАЦИЯСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ

МАТЕРИАЛЛАР АВТОР ӘШКӘРТҮЕНДӘ БАСТЫРЫЛА. АЛАРНЫ ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ УРНАШТЫРУ БАСМА МӘЙДАН БҮЛҮ БУЕНЧА ҮТКӘРЕЛГӘН ЖИРӘБӘ НӘТИҖӘЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛӘ

№ 7 Ибраһимов бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Мөхәммәдшина Р.Ж.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 14 Пионер бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Анисимов Д.А.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 14 Пионер бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Нәгыймова В.А.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 14 Пионер бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Гарипов Р.Ә.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

ЯКЫНАЕРМЫ АРА?

Мин кулыма китап алам

Китапны укучыга якынайту ул яхшы китап язуны да, авторның популярлыгын да, нәшрият эшчәнлеген дә, сәүдә системасының ничек оештырылуын да, реклама мөмкинлекләреннән файдалануны да үз эченә ала. Бер сүз белән әйткәндә, бу китапның идеясеннән башлап аны укучы кулына тапшыруның барлык этапларын да колачлый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шартлы рәвештә аны өч баскычка бүләргә мөмкин.

1. Яңа идеяләр, тәкъдимнәр булдыру өчен укучылар ихтыяҗын өйрәнү.
2. Нәшрият эшчәнлеге.
3. Китап сату.

Китап сәүдәсенең үз нечкәлекләре бар һәм ул икмәк, колбаса яки башка киң кулланышлы товар сатудан күпкә катлаулырак. Беренчедән, һәрбер китап үзенчә бердәнбер һәм аерым игътибар таләп итә. Китап язу – берничә айга, хәтта елларга сузыла торган эш, ә бу чорда аны укучыга тәкъдим итүнең алдан планлаштырылган ысуллары эшләми башлый. Китапны укучыга җиткерү юлында көтелмәгән каршылыклар килеп чыгарга мөмкин. Әйтик, сәяси үзгәрешләр. Автор, мәсәлән, ниндидер социаль челтәргә бәйле әсәр яза, ә китап өлгереп җитүгә, теге челтәр экстремистик дип игълан ителә. Ниндидер шәхесне данлаган әсәр яза. Чынлап та мактаулы шәхес ул – Советлар Союзы Герое, орденнары, медальләре бихисап. Кылган батырлыклары да сокланып тел шартлатырлык. Ә китап язылып бетүгә, теге кешенең чит ил шпионы булып баш китәрлек җинаятьләр кылганлыгы ачыклана. Һич югында бу әсәр дөнья күрү белән бик данлыклы, абруйлы бер шәхес аны гаепли торган рецензия язып чыга. Яки ниндидер бер псих авторны плагиатта гаепли, минем идеяне урлаган дип шау-шу куптара. Мондый көтелмәгән нәрсәләрне берничек тә санап, исәпкә алып бетерерлек түгел. Иң четерекле мизгелләрнең берсе шуңа бәйле: китап ул милли, мәдәни, әхлакый хәзинәләрне саклау һәм үстерү чарасы булу белән бергә товар да булып тора. Аны хасил итү өчен зур гына чыгымнар сарыфлана һәм нәшрият өчен табыш алу, һич югы чыгымнарны каплау иң беренче максатка әйләнә. Ә инде алдан корылган фаразларның көтелмәгән күренешләр аркасында җимерелүе сәүдә стратегиясен өр-яңадан карап чыгуны, төзәтүне таләп итә, димәк, өстәмә мәшәкатьләр һәм акча сорый.

Хәтта уңышлы идеяләр дә тиз генә файда китермәскә мөмкин. Хәтерегездә булса, элек китаплар гел диярлек каты тышлык белән чыга торган иде. Бер нәшрият китап базары үсешен, чит илләрдәге тенденцияләрне өйрәнеп, йомшак тышлыктан торган серия чыгара башлый. Тик каты тышлыкка өйрәнгән укучылар аңа борылып та карамый. Алар моңа күнексен өчен озак кына көтәргә туры килә. Хәзер инде йомшак тышлы арзанлы китаплар иң күп сатылучылардан исәпләнә.

Укучылар ихтыяҗын өйрәнү. Бу, бер яклап, бик әһәмиятле нәрсә инде. Төрле анкеталар, сораштырулар, аралашулар, социаль челтәрләрдәге китапка бәйле төркемнәрне анализлау һәм башка алымнар аша китап укучыларның ниндирәк әсәрләр укырга теләвен ачыклыйсың, булачак китаплар өчен темалар, жанрлар, юнәлешләр билгелисең. Ләкин бу да һәрвакыт көтелгән нәтиҗәләргә китерми. Беренчедән, иҗат ул – бәйсезлекне ярата торган шөгыль һәм автор укучылар зәвыгына яраклашырга, аларның ихтыяҗын канәгатьләндерергә атлыгып тормый. Ә мәҗбүр ителеп яки теләмичә язылган әсәрләрнең сыйфаты бик югары булмый. Икенчедән, укучыларның ихтыяҗы мәңгелек нәрсә түгел. Бүген ул бертөрле булса, иртәгә җәмгыятьтәге көтелмәгән борылышларга бәйле рәвештә үзгәрергә дә мөмкин. Шуңа күрә бик күп көч һәм вакыт таләп итә торган бу эшчәнлек туктаусыз рәвештә дәвам итәргә мәҗбүр. Зур нәшриятлар өчен бу – көймәңне комга терәмәүнең иң җилле ысулы. Бер китап белән уңышсызлык килеп чыкса да, икенчесе зур танылу табарга һәм берничә уңышсыз проектның чыгымнарын капларга мөмкин. Озак еллар буе даими эшләп килсә, укучылар ихтыяҗын өйрәнү хәзерге көн бурычларын канәгатьләндерү белән генә чикләнеп калмый, ә киләчәктә ниндирәк әсәрләр кирәк булачагын да күзалларга мөмкинлек бирә.

Китап нәшер итү. Монда барысы да ачык кебек инде. Тышлык яхшы булырга тиеш. Әгәр ул киштәдәге башка басмалардан аерылып, үзенә чакырып тора икән, укучы кулына тотып булса да караячак. Китапның исеме дә серле булырга, кызыксыну уятырга тиеш. Һәм, әлбәттә, аннотация... Менә минем өчен монысы иң авыры. Берничә сүз белән укучыны җәлеп итү, аны китапны актарып карарга, сатып алырга этәрү – авыр нәрсә. Шуңа күрәдер, бездә чыккан китапларның берсендә дә диярлек юньле аннотация юк. Миңа калса, һәр нәшриятта моны язу өчен махсус курслар узган берничә кешелек төркем булырга тиештер. Хезмәткәрләр санын арттыру да кирәкмидер, берничә кешене укытып чыгарасың да хезмәт хакына өстәмә ясыйсың. Барысы да җайлана шуннан соң.

Һәм киштәдәге китапны кулга алуның иң мөһим бер сәбәбе – авторның исеме. Мин чит ил нәшриятларын да, русныкыларны да күзәтеп барам. Алар менә ничек эшли... Әгәр берәр автор ниндидер әсәре белән популярлашып китә икән, аны рекламаларга, пропагандаларга тотыналар. Шунда ук икенче әсәрен язарга этәрәләр, кайбер очракларда ярыйсы гына суммада аванс та биреп куялар. Икенче китабы әзер булуга, өченчесен сорыйлар. Чит илләрдә хәтта киностудияләргә дә, һәртөрле премияләргә дә популярлашып килүче автор язган китапны нәшриятлар тәкъдим итә. Бер сүз белән әйткәндә, бер тапкыр популярлык казанган авторны алар тагы да ныграк күтәрә, рекламалый, популярлаштыра. Аның бөтен потенциалын кулланып, кызуында эшләтеп калырга омтыла. Бу, әлбәттә, табыш алу теләгенә дә бәйле. Шул ук вакытта язучы өчен дә файдалы. Матди яктан да, иҗат мөмкинлекләрен ачу җәһәтеннән дә. Кызганычка, бездә андый нәрсә юк. Бездә «сукыр тавыкка бар да бодай» дигән кебегрәк эшлиләр. Кибәге дә, бодае да бер өемдә ята. Аерып алып тәкъдим итмәгәч, бодае бик күренми һәм бөтен әдәбият кибәк өеме булып тоела.

Китап сату. Моның өчен әллә нәрсә кирәкми кебек инде. Иң беренче чиратта, китап кибетләре кирәк. Татарлар яши торган зур шәһәрләрнең төрле почмакларында, район үзәкләрендә, авылларда. Һәр авылда китап кибете ачу бик мәшәкатьле булып тоелса, моны авыл китапханәләрендә оештырырга була. Андый китапханәләр, гадәттә, мәдәният йорты тирәсендә бит инде, яшьләр биеп туйган арада шунда кереп утыра, китап актарган була, күрә, кызыксына. Монда хәтта артык чыгымлы реклама да кирәкми, авылда хәбәр тиз тарала, хәзер һәр җирдә диярлек авылдашлар төркеме бар, социаль челтәрләрдә китапханәләр төркемнәре эшли. Шундый-шундый китап кайтты, бәясе фәлән сум, дип игълан бирү дә җитә. Монда бер генә каршылык булырга мөмкин – китапларның бәясе. Тик анысы да хәл ителмәслек нәрсә түгел, басма хакын арзанайту юллары җитәрлек – гадирәк кәгазь, мәсәлән, юка тышлык, өстәмә бәяне бераз төшерү һ.б.

«Татмедиа» «Казан утлары» журналы белән эшләгән «Кесә китабы» сериясен сатуда бик уңышлы алым уйлап тапты. Ул аны район газеталары редакцияләре аша тәкъдим итте, интернетта туктаусыз рәвештә диярлек реклама барды. Моны яңача эшләүнең бер үрнәге итеп карарга кирәк. Китаплар турындагы хәбәр хәтта Татарстаннан читтә яшәгән татар авылларына һәм шәһәрләренә кадәр барып җитте. Алар китапларын интернет аша да тәкъдим итәләр, үзләренең дә китап кибете (shop.tatmedia.ru) бар, башка интернет-кибетләрдә дә алырга мөмкин.

Татарстан китап нәшриятының зур һәм бай булуын телим инде мин. Ул да заманга иярергә тырыша, эзләнә, нәрсәләрдер таба да. Сайтларында (tatkniga.ru) басма китапларны да, аларның электрон вариантларын да сатып алырга була, бушлай китапханәләре дә бар. Китапханәдән интернет эшләп торганда гына кулланырга мөмкин, чөнки ул китапларны фәкать сайтка кереп кенә укымалы, йөкләп ала торган түгел. Ләкин яхшырагы булмаганда андый шартлар да ярап тора. Һәм миңа иң нык ошаганы – аудиокитаплар. Беренчедән, аларның барысын да диярлек профессиональ актерлар яки авторлар үзләре укый. Икенчедән, йөкләп алырга һәм теләсә кайсы урында һәм вакытта тыңларга була. Өченчедән, бушлай.

Китапны укучыга якынайту чаралары, әлбәттә, моның белән генә бетми. Алар күп һәм бу темага аерым бер китап язарга мөмкин. Ә иң үтемлеләре, нинди сыйфатта узса да, әһәмиятен җуймый торганнары турында алдагы язмаларда сөйләшербез.

Марат КӘБИРОВ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге казанышлары өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча Яңа Савин районыннан ун баланың ата-анасы **Белоусов** Александр Евгеньевич, **Белоусова** Галина Викторовна; Мамадыш муниципаль районы буенча Югары Тәкәнеш авылыннан сигез баланың ата-анасы Саматов Рәис Баһаутдин улы, **Саматова** Гөлия Кәлфин кызы; Түбән Кама муниципаль районы буенча Түбән Кама шәһәреннән ун баланың ата-анасы **Михайлов** Вячеслав Иванович, **Михайлова** Зоя Петровна **Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале** белән бүләкләнде.

***

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Азнакай муниципаль районы буенча Әгер авылыннан алты бала анасы (шуларның бишесенә өч яшь тулган) **Хәмзина** Илсөя Мөнирҗан кызы, Актаныш муниципаль районы буенча Кыр-Каентүбә авылыннан биш бала анасы **Зарипова** Раилә Рәис кызы, Әлмәт муниципаль районы буенча Яңа Троицкий авылыннан алты бала анасы **Зуйкова** Гүзәл Риф кызы **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

***

«УҢЫШ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бозау караучысы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Демьянова** Любовь Романовнага, «Колос» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте сыер савучысы (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Матвеева** Ольга Николаевнага, «Рассвет агрофирмасы» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативының терлекләрне ясалма орлыкландыручысы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Михайлова** Лидия Николаевнага, «ӘНӘК» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Әтәс» бүлекчәсе бозау караучысы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Салихова** Альбина Мөдәрис кызына, «Вахитов исемендәге» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы сыер савучысы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Шәйхетдинова** Әлфия Нургали кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Хузангай» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Әлки районы) **Казанков** Владислав Егоровичка, «Вахитов исемендәге» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы механизаторы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Михайлов** Анатолий Ивановичка, «Татарстан» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Сәйпиев** Әмин Хатыйп улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының исәп һәм хисап бүлеге башлыгы **Билалова** Ландыш Аромат кызына; Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасары **Мурaтшин** Илшат Исмәгыйль улына; Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе **Павлов** Сергей Николаевичка; Казан шәһәренең «Уникс баскетбол клубы» җирле иҗтимагый оешмасы баш бухгалтеры **Һадиуллина** Резеда Рашад кызына; «АК БАРС» акционерлык коммерциячел банкы (гавами акционерлык җәмгыяте) Финанс департаменты директоры **Шәрәпов** Айрат Марат улына; Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны көйләү бүлеге башлыгы **Юсупова** Ирина Валерьевнага; «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе баш бухгалтеры – финанс идарәсе башлыгы **Буслаева** Ирина Сәлим кызына; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратның баш бухгалтеры – исәп һәм хисап идарәсе башлыгы **Матвеев** Олег Михайловичка **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Гармунчылар票 парады, Ваһаповка һәйкәл, салют...

30 АВГУСТТА КАЙДА НИНДИ ЧАРАЛАР КӨТЕЛӘ?

Республика һәм Шәһәр көнен быел да зурлап бәйрәм итәргә җыенабыз. Программа ниләр белән сөендерә? Һәр кеше үз күңеленә хуш килгән чараны таба алырмы? Матбугат очрашуында әнә шул хакта сөйләштеләр.

– Гадәттәгечә, бу көнне республика башкаласында һәм районнарында зур күңел ачу программасы әзерләнгән. Аны мөмкин кадәр төрләндерергә тырыштык. Традицион рәвештә һәр елны уздыра торган чараларыбыз да, яңалары да булачак, – диде «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында Татарстанның мәдәният министры урынбасары Юлия Әдһәмова.

Республика һәм шәһәр көнен бәйрәм итү елдагыча 30 августта Ратушада Казанның мактаулы гражданнарын хөрмәтләү тантанасы белән башланып китәчәк.

11.00 сәгатьтә Камал театры каршындагы мәйданда традицион «Уйнагыз, гармуннар!» халык иҗаты бәйрәме башланачак. Татарстанның атказанган артисты Фирдүс Тямаев җитәкләгән йөрештә гармунчылар һәм артистлар, милли киемнәрдәге халык шәһәрнең үзәк урамнары буйлап 1 Май мәйданына кадәр барачак. Бөтен республикадан һәм Россия төбәкләреннән меңнән артык гармунчы җыелачак, дип вәгъдә итә оештыручылар.

Шулай ук Камал театры каршындагы мәйданда **13.30 сәгатьтә** «Безнең заман» фестивале катнашучыларының гала-концерты башланачак.

11.00–22.00 сәгатьләрдә Меңьеллык паркында TatFuture цифрлы мәдәният бәйрәме, ә «Урам» экстрим паркында яшьләр өчен «Урам» музыка фестивале узачак.

13.00 сәгатьтә Казан Кремлендә мәдәният, тарих һәм заманча сәнгать өлкәсендә актуаль юнәлешләргә багышланган Tat Cult шәһәр мәдәнияте һәм сәнгате фестивале узачак. Быел фестивальне үткәрү урыны үзгәргән. Ул Милли китапханә территориясендә узачак. Тагын бер яңалык: фестиваль беренче тапкыр ике мәйданчыкта – Милли китапханәнең каршында һәм арткы ягында узачак.

14.00 сәгатьтә Кабан күле буенда «Милли кием» фестивале башлана. Каюм Насыйри урамында 600 җырчы һәм биюче катнашында «Казан сөлгесе» халык җыр-бию сәнгать фестивале үткәреләчәк.

15.00 сәгатьтә Казан ипподромында ат спорты бәйрәме оештырыла.

Шулай ук, быел Татар дәүләт филармониясе янындагы скверда халкыбызның мәшһүр җырчысы Рәшит Ваһаповка һәйкәл ачыла. Ваһапов фестивале лауреатлары концерт программасы да тәкъдим итәчәк.

Казан Башкарма комитетының мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов сүзләренчә, Россия халыкларының мәдәни мирасы елында җәмгыятьтә гражданлык татулыгын үстерү һәм ярдәм итүгә бәйле чараларга зур игътибар бирелә. Ел саен уздырылучы «Минем йортым – минем республикам» фестивалендә быел 4000гә якын катнашучыны көтәләр. Монда татар, рус, чуаш, мари һәм республикабызда яшәүче башка милләт вәкилләренең традицион мәдәниятләре тәкъдим ителәчәк.

18.00 сәгатьтә Игенчеләр сарае каршындагы мәйданда Александр Сладковский җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт симфоник оркестры һәм Россиянең атказанган артисты Аида Гарифуллина чыгыш ясаячак.

17.00–22.00 сәгатьләрдә «Казан» гаилә үзәге янында зур бәйрәм концерты узачак. Тамашаның төп кунаклары – Филүс Каһиров, Uma2rman («Уматурман») төркеме һәм яшь башкаручы Ваня Дмитриенко.

Республика һәм Шәһәр көненә багышланган чаралар бәйрәм салюты белән тәмамланачак.

Ләйсән САФИНА

Кыш корсагын җәй кайгырт

«Быел азрак тозлыйм», «Былтыргыларын да ашап бетермәдек әле», «Быел бу кадәр банка япмыйм». Хуҗабикәләр өчен шактый таныш сүзләрдер бу. Җәй саен кабатлана торганнары. Тик җәй саен үтәлми торганы да.

pxhere.com

Баксаң, быел банка ябучылар саны бераз гына булса да кимегән, ди. Төгәлрәк әйткәндә, консервация өчен товарларга ихтыяҗ, былтыргы саннар белән чагыштырганда, 20–25 процентка азайган. Ә менә кирәк-яраклар бәясе (гомуми чек) 15–30 процентка арткан.

Белгечләр моны нәрсә белән аңлата соң? Иң элек бар нәрсәнең дә кыйммәтләнүе тәэсир итә. Җәй айларын банка ябудан башка күз алдына да китерә алмаган кешеләр бер тапкыр кулланышта булган банкаларны кабат кулланырга, күрше-күләннәрдән артык калганын сорап торырга өйрәнгән хәзер. Күпчелек онлайн сәүдә мәйданчыкларын үз иткән. Биредә кайбер товарларны арзангарак та сатып алу мөмкин.

Консервация эшенә кызыксыну кимүнең тагын бер сәбәбен коронавирус пандемиясенә сылтый белгечләр. Әйтик, кешеләр хәзер сәламәтлеген күбрәк кайгырта. Шуңа да, банка ябып мәшәкатьләнү урынына берәр җиргә ял итәргә барып кайтуны кулайрак дип таба икән.

Уңган хуҗабикәләрдән саналган **скрипкачы Динә Закирова**га быел банка ябу мәшәкатьләре бик эләкмәгән.

– Әле бер нәрсә дә япмадым, ясамадым. Вакыт юк бит. Гадәттә, нәрсәдер ясасам, рецептын «Ютуб»тан карыйм. Менә ташкабак икрасы ясармын дип торам әле, җитешеп булса, – диде ул.

Арчадан Рәйдә Нигъмәтҗанова:

– Быел яшелчә һәм җиләк-җимеш елы булмаячак – иртә язда шундый хәбәрләр белән куркытып куярга өлгергәннәр иде. Авыл халкы имеш-мимешкә генә ышанып тормый бит, эшләп карый. Без дә шулай иттек. Елдагыча суганын да, кишер һәм чөгендерен дә, башкасын да күпләп утырттык. 70 төпкә якын помидор күчердек. Берсендә булмаса, икенчесендә, анысында да булмаса берәр төбендә булса да авыз итәрлек помидор булыр әле дип өметләндек. Хәзер рәхәтен күрәбез менә. Бакча яныннан үтсәм дә, помидор эләктереп китәм, көн буе помидор салаты ашыйбыз. Суганнарны җыеп алып куйдык инде. Уңыш мул, шөкер. Быел 35 банка кызыл карлыган һәм чия компоты яптык. Хәзер кыяр һәм помидорлар белән маташабыз, – ди.

Хезмәттәшебез Зөлфия Хәлиуллина бу статистик мәгълүматларга шикләнебрәк каравын яшерми. Киресенчә: банка ябып маташмаганнарның быел кызыксынуы көчәеп китмәдеме икән әле?

– Яшелчәме, җиләк-җимешме – мин барысын да туңдыру, катыру яклы идем. Әле: «Нәрсәгә банка ябып азапланасыз?» – дип, барчасын да сүгәм. Әмма, ни хикмәттер, быел мин дә консервацияләү белән маташтым, – ди ул. – Күбрәк ашка салып булырлык, башка төр ризык әзерләгәндә ярап куярлыкларын яптым. 650 граммлы банкаларга ташкабак икрасы, томат согында кыяр, солянка, лечо әзерләдем. Кайсы бишәр, кайсы дүртәр банка булгандыр. Быел уңыш мул булды бит. Әйтик, помидорлар тиз өлгерде. Аны озакка сузып булмый, хәзер һәм бүген эшкәртергә кирәк бит. «Сез япкан әйберләрне ашап бетерәсезме соң?» – дип, күпләрдән сорашканым бар. Бик күп әзерләүчеләр, банкаларның берсе дә калмый, ди. Күпләр җәй нигъмәтләрен ачып ашау өчен түгел, нәрсәдер ясар өчен куллана бит. Оныклары, балалары күп булганнар банкаларны шәһәргә дә биреп җибәрә. Шул ук солянка, борщ дигәннәренең дә банкада булганнары бик җайлы бит.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Хуҗабикәләр колагына

«Тәмле» салат

3 килограмм помидор, 4 килограмм кыяр кирәк була. Помидорны иттарткыч аша чыгарабыз, янына 3–4 тырнак изелгән сарымсак һәм вак итеп туралган 1 борыч кушабыз. 200 грамм көнбагыш мае, 3 аш кашыгы тоз салып, кайнатырга куябыз. 15 минут кайнагач, 200 грамм шикәр комы, 150 грамм серкә, 6–8 түгәрәк кара борыч салып болгатабыз. Түгәрәкләп юка итеп туралган кыярны кушып, 15 минут кайнатабыз һәм банкаларга тутырабыз.

Кыяр тозлау

3 литрлы стерильләштерелгән банкага түгәрәкләп туралган 1 кишер, 1 баш сарымсак, икешәр кара карлыган, чия яфраклары, 1 укроп, исле кара борыч салып куябыз. Алар өстенә кыяр тезәбез. Кайнап чыккан су салып, 15 минут тотабыз. Суны кәстрүлгә кире агызып, янә кайнатабыз һәм янә шундый ук эшне башкарабыз. Өченче тапкыр су салганда суга 10 бал кашыгы шикәр комы, 100 грамм аш серкәсе өстибез һәм кайнатып, кыярлы банкаларга салабыз. Банкаларны тимер капкач белән ябып куяр алдыннан 1 бал кашыгы лимон серкәсе салып чыгабыз.

«Галиябану» туган авыл

Балтач районының Шода авылы – үзенең табигате, кешеләре һәм, гомумән, мохите белән татар халкын «Галиябану»лы иткән авыл. 1916 елда Мирхәйдәр Фәйзи үзенең көндәлегенә: «Шодада көннәр бик-бик күңелле уза. Авыл минем күңелемнең кәгъбәсе булганга, Шоданың авыллыгы мөкәммәл булып, күптән көткән бәхетемә юлыкканга бик шат идем. Һәм алданмадым», – дип яза.

Ул бирегә абыйсы Сәетгәрәйләргә кунакка килгән була. Шул ук елның 8 октябрендә көндәлегендә янәдән әлеге сәяхәтен искә ала: «Казан ягы авылларында йөреп кайттым. Бу яктагы авылларда күргән күренешләрдән файдаланып, «Сәгадәтбану» исемле пьеса язу уе туды», – ди ул. Ике ай дигәндә, драматург ниятен тормышка ашыра, пьеса языла. Мирхәйдәр Фәйзи аны режиссер Вәлиулла Мортазин-Иманскийга җибәрә. Режиссер исә драматургка үзенең киңәшләрен бирә һәм «Сәгадәтбану» исемен «Галиябану»га алыштыра. Сәбәбе: «сәгадәт» сүзе гарәпчәдән «бәхет» дип тәрҗемә ителә. Ахыры фаҗигале тәмамланган әсәргә бу бик килешеп бетмәс иде.

Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ын кайсы авыл сәхнәсендә генә уйнамадылар икән?! Шул ук вакытта Мирхәйдәр Фәйзи үзе дә, аның иҗаты да ничектер бераз күләгәдәрәк калып килә. Бүгенгәчә дөнья күрмәгән, китап буларак басылып чыгып, халыкка җиткерелмәгән көндәлекләре генә дә – моның ачык мисалы. Югыйсә ул көндәлекләр революциягә хәтле татар авылларының яшәешен, гореф-гадәтләрен тулысы белән, фактларга бәйләп ачып бирер иде.

Гәрчә монда тумаса да

Гомеренең санаулы көннәрен генә Балтач районында уздырган булса да, Мирхәйдәр Фәйзине балтачлылар бик якын итәләр. Биредә аның музей-утары бар, ел саен туган көне уңаеннан чаралар үткәрелә, кунаклар чакырыла. Инде менә янәдән бер зур проект, Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе гранты ярдәмендә, Мәдәният министрлыгы белән берлектә Мирхәйдәр Фәйзинең Шода авылында урнашкан музей-утарында «Uрам» театр фестивален уздырдылар. Фестивальгә уннан артык халык театрыннан гариза килгән, комиссия, шулар арасыннан дүртесен сайлап алып, тамашачыга тәкъдим итте.

Август аеның җылы матур киче. Авыл кичке бер сихри рәхәтлеккә чумган. Әлеге күренешкә ниндидер серлелек өстәп, алма бакчасының түренә урнашкан йорт тәрәзәсеннән «Галиябану» җыры ишетелә. Ул арада биек йортның балконыннан «Галиябану» үзе дә күренә. Әлеге күренеш, елларны кирегә борып, Галиябанулар, Хәлилләр чорына кайтарды да куйды.

– Халык театрлары арасында фестивальләр күп. Шулай да «Uрам» театр фестивале уникаль. Уникальлеге – иң беренче чиратта, аның үткәрелү урынында. Шәһәрдән, хәтта район үзәгеннән дә читтәге зур булмаган авылда республика күләмендәге фестиваль узды. Уникальлекнең икенчесе – ачык һавада узуы. Аның исеме дә – «Uрам» фестивале. Оештыручылар урынны да бик уңышлы сайлаганнар. Мирхәйдәр Фәйзи музей-утары, янында гына мәчет, балалар бакчасы.

Автор фотолары

Гадәти мәдәният йортында чыгыш ясауга караганда, техник яктан авырлыклар тудырса да, урам сәхнәсендә чыгыш ясауның үзенә күрә бер романтикасы бар. Спектакль ахырына якынлашканда көн кичкә авышты, күктә йолдызлар кабынды. Болар бар да бер сихрилек өсти. Шушындый фестивальгә нигез салынуга куанып, бик канәгать булып кайттым. Чыгыш ясаган коллективларның эшләрендә, әлбәттә инде, режиссер кытлыгы күренә. Яшерен-батырын түгел, мондый кытлык профессиональ театрларда да бар, халык театрлары арасында инде ул бигрәк тә сизелә. Киләчәктә режиссерлар белән эшләп, тагын да яхшырак спектакльләр күрербез дип уйлыйм. Катнашучылар, үзешчән артистлар бик сокландырды. Олы-олы апалар, абыйлар, урта буын, яшьләр. Аларның һәркайсының хуҗалыклары, гаиләләре, төп эшләре бар. Шулай да алар, бөтен мәшәкатьләрен читкә куеп, театр дөньясына чумалар, репетицияләргә йөриләр. Театрга булган мәхәббәтләре өчен аларга зур рәхмәт, – диде комиссия әгъзасы, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты Резеда Сәлахова.

Казан кунаклары мастер-класслар күрсәттеләр. Берәүләр грим салды, икенчеләре сәхнәдә чыгыш ясау серләренә өйрәтте. Профессионалларның фикерләре, эш алымнары, әлбәттә, үзешчәннәр өчен бик кадерле.

Хәер, мастер-класслардан тамашачылар да читтә калмады. Рәхәтләнеп катнаштылар, артистлар белән аралаштылар. Иң куанычлысы: авыл халкы театр сәхнәләрендә бара торган бөтен репертуарны белә, теге яки бу спектакльгә карата фикерләрен җиткерделәр. Әле сезон ябылыр алдыннан гына Тинчурин театры сәхнәсендә куелган «Мәдинә» спектаклен дә карарга өлгергәннәр. Аларның һәр күренешне йөрәк аша үткәреп сөйләүләрен сокланып тыңлап тордым. Югыйсә без «гади авыл тамашачысы» дияргә яратабыз.

– Мирхәйдәр Фәйзинең музей-утарында театр сөючеләрне җыйнау минем зур хыялым иде. Аны тормышка ашыруга булышканы өчен Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Готыф улы Әхмәтовка, районыбызның мәдәният хезмәткәрләренә рәхмәт. Шода авылының меңнән артык кеше яшәгән чорлары да булган. Ул – Советлар Союзы Герое, Тукай премиясе лауреатын биргән авыл. Әлеге фестиваль авылга яңа сулыш бирсен, җан өрсен иде, дигән теләктә калабыз, – диде Балтач районы Башкарма комитет җитәкчесе Айдар Хәйретдинов.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Виноград үстерүче Айрат:

«Миңа берәү дә ышанмады»

Шөгыль

Кама Тамагы районына килеп кергәндә, виноград плантацияләренә тап буласың. Безнең җирдә дә виноградны шулай күпләп үстереп буламыни, дип гаҗәпләнүчеләр бер без генә түгелдер, мөгаен. Монда узып китүчеләр дә еш туктый, хәтта экскурсиягә дип махсус килүчеләр дә бар.

Моннан 8 ел элек Айрат Ялалетдиновның бу нияте барып чыгар дип берәү дә уйламаган. Татарстан җирендә көньяк җимешен үстерү күпләргә сәер тоелгандыр. Ә ул тәвәккәлләгән. Ульян өлкәсендә бер танышының виноград үстерүенә кызыгып, үз эшен башлаган.

– Белгечлегем буенча юрист мин. Җаныма тынычлык табар өчен, җир эшен сайладым. Хатыным каршы килмәде. Казандагы тормышны калдырып, Кама Тамагына күчендек. Иң элек җир алдым, аннан соң үсентеләр утырта башладык. Дәүләттән алган 1 миллион 500 мең сумлык грант ярдәм итте, – ди ул. – Виноград үстерүнең берние юк аның. Иң мөһиме – дөрес итеп утырту. Һәр төпне 80 сантиметр тирәнлектә чокыр казып утыртасы. Үсентеләрне үрмәләтү өчен махсус чыбыклар кирәк. Кышка без ботакларны йә җиргә, йә саламга күмеп куябыз.

Айрат виноградның Татарстан җирләренә яраклысын, тиз өлгерә торган сортларын сайлап утырта. Бүген аның плантациясендә 80нән артык сорт бар. Виноградлар ел да җимеш биреп сөендерә икән. Ул хәзер җимешләрен дә, үсентеләрен дә сата.

– Виноградны каядыр барып сатканыбыз юк. Кибетләргә дә таратмыйбыз. Кешеләр монда үскәнен белеп, килеп алалар. Күбрәк туристлар сатып алып китә. Үз гомеребездә бары тик ике тапкыр гына Казан базарына барып сатып кайттык. Килеп алучылар күп булгач, баруны туктаттык. Быел кара бөрлегән дә утырттык. Күп итеп «Виктория» җиләге уңышы да алдык. Анысын да килеп алып бетерделәр. Тормышыбыз зарланырлык түгел. Эшләгәч, ашарлык та, яшәрлек тә акча була. Әмма виноград үстерүнең шул ягы бар: чын табыш алу өчен озак тырышырга, ким дигәндә бер куактан 15 килограмм уңыш алырга кирәк, – ди эшмәкәр.

Айратның плантацияләрендәге виноградлар 95 көн эчендә өлгерә. Без килгәндә өлгермәгәннәр иде әле. Әмма ботаклар уңыштан сыгылып тора. Узган ел 31 августта бар виноградын сатып бетергән инде ул. Быел язның соңга калуы аркасында, әле виноград уңышы сентябрьдә генә сөендерәчәк.

Айрат виноград үскәнен генә көтеп утыра торган егет түгел икән. Быел кышын теплицасында кыякка суган үстереп саткан. Әмма ял итмичә эшләү үзен сиздергән. Яшерми – бик арган. Шуңа да кыш көне ял итәргә исәпләп тора. Басуда элек гаиләсе белән генә эшләсәләр, хәзер ярдәм итүчеләре бар. Махсус эшчеләр яллаган. Әмма аларның да эш рәтен белгәннәрен сайлый икән. Белемле кешеләргә ихтыяҗ зур. Ә уңышны җыйганда эшчеләр саны арта, ди ул.

– Виноград уңышы ел саен бертөрле булмый. Узган ел бөтенләй өмет итмәгән виноград сортлары ишелеп уңды. Быел әллә ни күп булмас кебек. Тик без булганына шөкер итәргә өйрәндек инде, – ди ул. – Хыялларым күп минем. Шәраб ясыйсым килә. Виноградның шәраб ясый торган махсус сортларын да үстерәм. Менә шуны тормышка ашырасы иде.

Айрат Чувашиянең Батыр районында туып-үскән. Тормыш иптәше – Ульян якларыннан. Күңелләренә хуш килгән Кама Тамагында ике ул үстереп гомер итәләр.

Камский-виноградник.рф

Димәк, дәвамчылары үсеп килә. Ике улына өйрәтәсе эшләре күп әле Айратның. Әле киләчәктә виноград рәтләрен дә зурайтып җибәрмәкче. Иң мөһиме – кояш җылысы һәм сатып алучыларның күп булуы кирәк аңа. Калганын булдырырга өйрәнгән инде ул!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6688 данә
Гомуми тираж – 15838 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 323

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+